РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» апреля 2024 ел г. Альметьевск № 1268

Опека һәм попечительлек өлкәсендә
Татарстан Республикасы дәүләт
вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен
җаваплы вазифаи затны билгеләү
турында

Россия Федерациясе гражданлык кодексы, «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының опека һәм попечительлек өлкәсендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека» идарәсе башлыгы М.Н. Шамсуллинаны җаваплы вазифаи зат итеп билгеләргә.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека» идарәсе башлыгы М.Н. Шамсуллинага түбәндәге мәсьәләләр буенча боерык рәвешендә чыгарыла торган хокукый актларга һәм башка документларга имза салу хокукын бирергә:

- балигъ булмаганнарны яисә суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган затларны опекага алу һәм юкка чыгару;
- балигъ булмаганнарга карата попечительлек билгеләү;
- опекуннар һәм попечительләр билгеләү;
- опекуннарны һәм попечительләрне үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәүдән азат итү яисә читләштерү;
- уллыкка (кызлыкка) алуга рөхсәт;
- ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тәрбияләү өчен акча билгеләү;
- банклар һәм башка кредит учреждениеләрендә балигъ булмаган, хокукка сәләтсез һәм хокукка сәләте чикләнгән гражданнарның акчаларын алу өчен рөхсәт бирү;
- балигъ булмаганнарның, хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте

заказ № 1-851

чикләнгән затларның мөлкәтен тартып алу, шул исәптән алмаштыру, бүләк итү буенча алыш-бирешләр, аны наемга (арендага), түләүсез файдалануга яисә залогка бирү, күрсәтелгән затларга караган хокуклардан баш тартуга китерә торган килешүләргә тапшыру, милекне бүлү, аннан өлеш бүлеп бирү, шулай ук балигъ булмаганнарның, хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән затларның мөлкәтен киметүгә китерә торган теләсә нинди башка алыш-бирешләр кылуга рөхсәт бирү;

- әлеге торак урын милекчесенең опекада яисә попечительлектә яшәүче яисә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балигъ булмаган гаилә әгъзалары (опека һәм попечительлек органына бу хакта билгеле) шул вакытта күрсәтелгән затларның хокукларына яисә законда саклана торган мәнфәгатьләренә кагылса, торак урынны читләштерү буенча килешү төзүгә рөхсәт бирү;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә социаль наем шартнамәләре буенча бирелгән һәм әлеге торак биналарны яллаучыларның гаилә әгъзалары булып торучы балигъ булмаган, эшкә сәләтсез яки чикләнгән эшкә сәләтле гражданнар яши торган торак урыннарын алмашуга рөхсәт бирү;

- балигъ булмаганнарның, эшкә сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән затларның сатыла торган торак урынын сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга рөхсәт бирү;

- ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен торак бинага хокукны саклап калу;

- ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә бирү яки ятим балалар яисә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган барлык төрдәге балалар учреждениеләренә тапшыру;

- баланы (балаларны) тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирү турында тәрбиягә бала алучы ата-аналар белән шартнамәләр төзү;

- ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, хокуктан файдалануга сәләтсез гражданнарны теркәп исәпкә алудан төшерү өчен рөхсәт бирү;

- эмансипация;

- 16 яшькә җиткән затларга никахлашуга рөхсәт бирү;

- Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә балигъ булмаган баланың фамилиясен, исемен, атасының исемен бирү яисә үзгәртү;

- баланың гомеренә яисә сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда опека һәм попечительлек органы баланы ата-анасыннан (аларның берсеннән) яки ул тәрбияләнгән башка кешеләрдән шунда ук алырга хокуклы;

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека» идарәсе эшчәнлегенә бәйле хисапларны тутыру һәм тапшыру;

3. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека» идарәсе башлыгына (Шамсуллина М.Н.) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актларны һәм башка документларны тиешле теркәүне һәм саклауны тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәгариф идарәсенә (Павловская И.А.) Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека» идарәсе күрсәтмәсе һәм «Тәрбиягә бала алучы гаилә төзү турында» шартнамә.нигезендә тәрбиягә бала алучы гаиләләргә опекага (попечительлеккә) тапшырылган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны матди яктан тәэмин итү өчен ай саен түләнә торган түләүне һәм үз бурычларын түләүле нигездә үтәүче опекуннарга һәм попечительләргә тиешле түләүне тәэмин итәргә.

4. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Опека һәм попечительлек өлкәсендә вәкаләтләр тапшыру турында» 2015 елның 16 февралендәге 305 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек өлкәсендә вәкаләтләр тапшыру турында» 2015 елның 16 февралендәге 305 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 25 августындагы 907 номерлы.

5. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — А.Р. Исхаков